**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау тиемер юл станциясе поселогы, Совет ур., 13

**СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**17 апрель 2019 ел** **№ 121**

**2018 нче елның 29 нчы мартындагы 78 нче номерлы Совет карары белән расланган, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында**

«2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы, 2014 нче елның 29 нчы декабрендәге 458-ФЗ номерлы «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында»гы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында»гы Федераль законнар, Россия Федерациясенең аерым закон актлары һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану»ы, 2004 нче елның 28 нче июнендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы Законы белән, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Уставына таянып, Красносельский авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2018 нче елның 29 нчы мартындагы 78 нче номерлы (2018 нче елның 13 нче сентябрендәге 90 нчы номерлы Совет карары редакциясендә) Красносельский авыл җирлеге Советының карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенен Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.1 пунктта:

а) 9 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен Красносельский авыл җирлеге Советы тарафыннан раслау, аларның үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;»;

б) 14 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14) каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортта ташу эшчәнлеген оештыруда катнашу;»;

1.2. түбәндәге эчтәлекле 16 нчы пунктчаны 3.2.1 нче пунктка өстәргә:

«16) 1992 нче елның 7 нче февралендәге 2300-1 номерлы «Кулланучылар хокукларын яклау турында»гы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру»;»;

1.3. 4.2 пунктының 7 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортта ташу эшчәнлеген оештыруда катнашу;»

1.4. 4.5 пунктының 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) күпфатирлы йорттагы биналарны яңадан төзүне һәм яңадан планлаштыруны килештерү;»;

2. Әлеге карарны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru, һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып халыкка җиткерергә.

Совет рәисе
Красносельский авыл җирлеге Башлыгы Р.Г.Кәлимуллин